МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2020 г.Казань № 512

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 5 августында 6800 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә аерым административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 санлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү сәбәпле, б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне, расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.07.2020 ел. № 512 боерыгы белән расланган

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә административ регламентларга кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2012 елның 6 июнендәге 383 номерлы «Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан булдырылган концлагерьлар, гетто, ирексезләп асрауның башка урыннарының балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 27.10.2014 ел № 590, 07.06.2016 ел № 317, 10.10.2016 ел № 572, 08.06.2017 ел № 351, 07.05.2018 ел № 347, 19.09.2018 ел № 892, 13.05.2019 ел № 362, 14.11.2019 ел № 1022 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан булдырылган концлагерьлар, гетто, ирексезләп асрауның башка урыннарының балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.4.3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - Министрлык) http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 4 сентябрендәге 445н номерлы боерыгы белән расланган Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан төзелгән концлагерьлар, гетто, мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук биргән таныклыкларны рәсмиләштерү, бирү һәм исәпкә алу тәртибенең (алга таба - Тәртип) 1 п.1, 7 п.»;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п. (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2012 елның 6 июнендәге 383 номерлы «Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветеранының гаилә әгъзасы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 19.06.2014 ел № 333, 12.04.2016 ел № 200, 08.06.2017 ел № 348, 07.05.2018 ел № 347, 18.09.2018 ел № 859, 13.05.2019 ел № 362, 14.11.2019 ел № 1022 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветеранының гаилә әгъзасы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.4.3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - Министрлык) http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт

телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы «Ветераннар турында» Федераль законның (алга таба - 5-ФЗ номерлы Федераль закон) 28 ст.; Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының 2000 елның 11 октябрендәге 69 номерлы карары белән расланган Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының һәм «Ветераннар турында» Федераль законда билгеләнгән башка категориядәге гражданнарның хокукларын һәм ташламаларын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында күрсәтмәнең (алга таба - 69 номерлы Күрсәтмә) 2.16 п.; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 20 июнендәге 519 номерлы «Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалиды, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераны таныклыгы турында» карарының 2 п.»;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль законнар» сүзләрен «2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п. (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы» графасына «Федераль закон» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

«Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы Тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2012 елның 5 июлендәге 514 номерлы «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 06.06.2014 ел № 309, 22.06.2015 ел № 425, 07.06.2016 ел № 317, 08.06.2017 ел № 350, 07.05.2018 ел № 347, 19.09.2018 ел № 892, 09.01.2019 ел № 8, 13.05.2019 ел № 362, 14.11.2019 ел № 1022, 10.02.2020 ел № 84 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - Министрлык) http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба – 210 ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы «Ветераннар турында» Федераль законның 28 ст. (алга таба - 5-ФЗ номерлы Федераль закон); Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 5 октябрендәге 1122 номерлы карары белән расланган Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыкларын тутыру, бирү һәм исәпкә алу тәртибе турында күрсәтмәнең (алга таба - 1122 номерлы Күрсәтмә) 1 п., 8 п.;

2.5 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «69 номерлы Күрсәтмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының 2000 елның 11 октябрендәге 69 номерлы карары белән расланган Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының һәм «Ветераннар турында» Федераль законда билгеләнгән башка категориядәге гражданнарның хокукларын һәм ташламаларын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында күрсәтмә» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п. (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.14 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы Тәртип» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы Тәртип)» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы» графасында «Федераль закон» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга.